

2017 ел Россиядә Экология елы дип игълан ителде. Экология елы кысаларында Кадошкино районы Большие Поляны гомуми топ белем биргән мәктәптә «Кошларга ярдәм итик» дигән экология акциясе  vткән.
Чаранын максаты укучыларны Кошлар коне тарихы белән таныштыру, аларга булдыра алган кадәр файда һәм яхшылыклар да башкару иде. Педагоглар коллективы тагы экологик грамоталылыкны арттыру, тирә- якка кызыксыну булдыру, Жир-анабызны саклау кебек сыйфатлар остендә торле чаралар аркылы булдырдылар.      Мәсәлән, башлангыч сыйныф укытучылары Адилә Фәрит кызы Байбекова, Римма Зәкәрья кызы Ляпина Халыкара кошлар конена багышлап экологик дәресләр (кунаклар да чакырганнар) vткәрделәр. Алар Халыкара кон тарихы, кошлар тормышы һәм туган як кошлары турында сойләгәч, укучылары якын дусларыбыз булган кошлар турында шигырьләр яттан сойләделәр, рәсем конкурсында, викториналарда катнаштылар, республикабызда “Кошлар йорты» акциясендә катнашып призлы урыннар яуладылар. Атналык кvләмендә ясаган кош ояларын мәктәп тирәсенә элгәч, сыерчыклар vз итеп шунда яши дә башладылар.